Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Урал торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү буенча

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

12 ноябрь 2025 ел № 8

2025 елның 20 мартындагы«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Урал торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенеә керүче Урал торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр бәлигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның якын туганнарыннан (ата-аналары, тормыш иптәшләре), Россия Армиясе сафларында хәрби хезмәт узучылардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Урал торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Урал торак пунктында су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су ташу һәм бирү (суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- Урал торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урамнарны энергияне саклый торган лампалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлау.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М.Н.Мусин